Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Иске Чаллы авыл Советы
КАРАРЫ.

2018 нче елның 20 нче ноябреннән 30№

“2018 елның 18 ноябрендә ТР Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре турында”

Федераль законның “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 70 статьясы, Федераль законның “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 22 статьясы нигезендә һәм 2018 елның 18 ноябрендә узган референдумда тавыш бирү йомгаклары турында участок сайлау комиссиясенең 720, 734 һәм 745 номерлы беркетмәләре (Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге башкарма комитеты) нигезендә авыл җирлеге Советы Карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә узган үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны узган, ә референдум нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. “Сез яшәү урыны буенча Иске Чаллы авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган, ләкин 1 нче группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, биш һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, кондезге формада белем алучы студентлардан һәм 80 яшькә җиткән кешеләрдән тыш, 2019 елда һәр кешедән 600 сум үзара салым алыну һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган салым акчаларын түбәндәге эшләрне үтәү өчен куллану белән килешәсезме:

- Иске Чаллы авыл җирлеге эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (җир өстенә туфрак, ком, вак таш сибү, торак пункт эчендәге юл кырыйларын чабу, урамнарны грейдерлау, урамнарны кардан чистарту, чүплекләрне чистарту)- 240 сум;

- Иске Чаллы авыл җирлеге торак пунктларында су челтәрләрен реконструкцияләү һәм су белән тәэмин итү белән бәйле чыгымнар буенча проект-смета эшләре башкару, су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, территорияне койма белән әйләндереп алу һәм су башняларын буяу, күлләрне төзекләндерү -140 сум;

- Иске Чаллы авыл җирлеге торак пунктларында урам утларын урнаштыруга материал (яктырткычлар) сатып алу, яктырту җиһазлары урнаштыру буенча электромонтаж эшләре, урамнарны яктырту өчен түләү -155 сум;

- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү, контейнерлар сатып алу, белгеч эше өчен түләү-65сум" мәсьәләрен чишү буенча карар кабул ителгән дип танырга.

Референдумда катнашучылар исемлегендә тавыш бирү тәмамланган вакытка 404 кеше кертелгән;

Сайлаучыларның референдумда катнашучылар саны - 385, бу 95,30 % тәшкил итә.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл жирлеге референдумының тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга.

4.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл жирлеге чикләрендә урнашкан 18 яшькә җиткән барлык гражданнар, 1 нче группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, биш һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм 80 яшькә җиткән кешеләрдән тыш, үзара салым акчаларын барлык гражданнар карар чыкканнан соң 12 ай эчендә түләргә.

5. Әлеге карарны Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга.

Әлки муниципаль районы
Иске Чаллы авыл Советы Рәисе,
авыл җирлеге башлыгы

Исхаков М.Г.